КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 март г.Казань № 211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1036 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче; 2016 ел, 27 июль, 517 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 805 нче; 2018 ел, 4 июль, 552 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1052 нче; 2018 ел, 18 декабрь, 1160 нчы; 2019 ел, 21 март, 197 нче; 2019 ел, 9 декабрь, 1130 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» 2005 елның 28 апрелендәге ПУ-147 номерлы, «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентя-

брендәге ПУ-511 номерлы указлары нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 10 октябрендәге б-2380 нче боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасындагы Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм мондый мәгълүмат белән алмашу, муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр булганда һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыру һәм үткәрү, янгыннарны Янгынга каршы дәүләт хезмәте көчләре белән сүндерүне оештыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгына тапшыру турындагы килешүне тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

7 нче пунктта:

икенче абзацта «218» һәм «3 155,1» саннарын шул ук эзлеклелектә «221,5» һәм «3 109,0» саннарына алыштырырга;

өченче абзацта «79,5» һәм «876,1» саннарын шул ук эзлеклелектә «76» һәм «1 029,3» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.2 нче пунктның җиденче абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләренә алыштырырга;

4.1 нче пунктның 4.1.20 нче пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен;

Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планын эшләүне һәм раслауны.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин